# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«24» 12 2019 ел Яр Чаллы ш. № 5384

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара мультидисциплинар бригадалар төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру турында» 1999 елның 23 маендагы 432 номерлы карарын, «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2019 елның 19 августындагы 637/1652 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының уртак боерыгын тормышка ашыру максатында

## КАРАР БИРӘ:

1. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара мультидисциплинар бригадалар төзергә.

2. Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара мультидисциплинар бригадалар турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара мультидисциплинар бригадалар составларын 2-15 нче кушымталар нигезендә расларга.

4. «Тукай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы Г.Г. Сабирҗановка, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы Э.Н. Ахуновага, Татарстан

Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районында «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры С.Н. Шәеховага, «Тукай картлар һәм инвалидлар интернат-йорты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе директоры Л.Т. Хөсәеновага өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын кертү буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен һәм Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертүне контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Бариев Илфак Шамил улына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24.12 № 557

номерлы карарына 1 кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча ведомствоара мультидисциплинар бригадалар төзү турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә ведомствоара мультидисциплинар бригадаларны формалаштыру һәм эшчәнлеген оештыру буенча оештыру-методик нигез булып тора.

1.2. Мультидисциплинар бригада-сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү органнарының гражданин белән эшләүнең һәр юнәлешендә комплекслы сыйфатлы ярдәм күрсәтү һәм социаль хезмәтләр күрсәтү максаты белән даими яки вакытлыча оештырылган, үз эшчәнлеген катнашучылар белән түбәндәге төп мәсьәләләр буенча аралашу юлы белән гамәлгә ашыручы хезмәткәрләре төркеме: һәр катнашучының эш максатлары, СДУ хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының хәзерге торышы, тормыш эшчәнлегенең агымдагы чикләүләре.

1.3. Ведомствоара мультидисциплинар бригада үз эшчәнлеген мәгариф, опека һәм попечительлек, эчке эшләр органнары һәм оешмалары, иҗтимагый һәм башка оешмалар, төрле оештыру-хокукый формадагы, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра ала.

1.4. Ведомствоара мультидисциплинар бригада Башкарма комитет Җитәкчесе боерыгы белән төзелә һәм бетерелә.

1.5. Ведомствоара мультидисциплинар бригада муниципаль районда сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре хезмәткәрләреннән оештырыла: Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районында «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү үзәге), «Тукай картлар һәм инвалидлар интернат-йорты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе һәм «Тукай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.

2. Ведомствоара мультидисциплинар бригаданың максатлары һәм бурычлары

2.1. Ведомствоара мультидисциплинар бригада эшчәнлегенең төп максатлары булып торар:

- чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнарны ачыклау, озак вакыт карау системасында катнашучылар арасында, озак вакыт карау буенча социаль һәм медицина хезмәтләре җыелмасын һәм күләмен билгеләү өчен, кирәкле мәгълүмат белән алмашу;

- чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнарны озак вакыт карау буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү;

- озак вакыт карау системасын булдыру һәм үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыруга мониторинг һәм контроль;

- чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнарның гомер озынлыгын арттыру, үлем санын киметү, тормыш сыйфатын яхшырту;

- социаль хезмәт алучыларга социаль хезмәтләр күрсәтүнең ачыклыгын һәм адреслылыгын тәэмин итү;

- чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнарга карата үткәрелә торган карап тәрбияләү, тернәкләндерү һәм реабилитация чараларының максималь уңай нәтиҗәләренә ирешү;

- чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнарның туганнарына һәм карауда катнашучы башка затларга «Карау-тәрбияләү мәктәбе» стационар алыштыру технологиясе кысаларында мәгълүмат бирү һәм укыту;

- өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өчен гадәти өй шартларында оптималь мөмкин булган тормыш дәрәҗәсенә һәм социаль адаптациягә ирешү;

- гаиләдә психик травма хәлләрнең, нерв-психик киеренкелек нәтиҗәләрен бетерүне тәэмин итүче, үзгәрүче шартларга җайлашу һәм сәламәтлеккә мотивация тудыру өчен шәхси алшартлар формалаштыра торган, социумда актив тормыш алып барырга этәрүче уңай шартлар һәм психологик атмосфера тудыру;

- медицина оешмаларының һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең хезмәт күрсәтүләренә ихтыяҗны киметү.

2.2. Ведомствоара мультидисциплинар бригада бурычлары:

- читләр кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданның физик халәтенә, функциональ статусына, психик сәламәтлегенә комплекслы бәя бирү һәм дәвалау-реабилитация чаралары планын төзү (сәламәтлек саклау учреждениесе);

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 19 августындагы 637/1652 номерлы уртак боерыгы нигезендә өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) тормыш эшчәнлегенә карата булган чикләүләр һәм аларны карауны оештыру буенча рекомендацияләр турында расланган форма буенча белешмә төзү;

- медицина оешмасы белешмәләрен, гражданга социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен, гражданның (аның законлы вәкиленең) мәгълүмати ризалыгы булган очракта, яшәү урыны буенча социаль яклау бүлегенә җибәрү;

- типлаштыру – гражданнарның озак вакыт карауда реаль ихтыяҗларын ачыклау;

- маршрутлаштыру – озак вакыт карау буенча хезмәтләр күрсәтүнең оптималь формасын билгеләү;

- чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнарны ачыклаганда һәм аларга озак вакыт карау буенча хезмәтләр күрсәтүне оештырганда, ведомствоара хезмәттәшлек;

- чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнар өчен гаилә тәрбиясенә ярдәм итү;

- озак вакыт карау буенча хезмәтләр алу мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат бирү;

- медицина ярдәмен һәм социаль хезмәт күрсәтүне дә (диагностика, дәвалау, реабилитация, психологик ярдәм күрсәтү, карау) кертеп, кирәкле ярдәм күрсәтүнең өзлексезлеген, дәвамчанлыгын һәм аның барлык өлешләренең үзара бәйләнешен тәэмин итү.

## 3. Ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

3.1. Ведомствоара мультидисциплинар бригада составына түбәндәгеләрне кертү максатка ярашлы: табиб-терапевт һәм/яки гериатр табиб, тар профиль табиблары (кирәк булганда), реабилитолог, урта медицина персоналы, паллиатив ярдәм табибы (кирәк булганда), социаль хезмәткәр һәм башкалар.

3.2. Мультидисциплинар бригада составын формалаштыру гражданинның сәламәтлеге торышына, үз-үзенә хезмәт күрсәтү сәләтен югалту дәрәҗәсенә, аның социаль эшчәнлеге дәрәҗәсенә һәм башка проблемаларга бәйле.

## 4. Ведомствоара мультидисциплинар бригада эшен оештыру

4.1. «Тукай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, социаль яклау бүлеге, «Тукай муниципаль районындагы «Шәфкать» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, «Тукай картлар һәм инвалидлар интернат-йорты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе арасында ведомствоара хезмәттәшлек, чит кешеләр ярдәменә даими мохтаҗ гражданнарны ачыклаганда һәм аларга озак вакыт карау буенча хезмәтләр күрсәтүне оештырганда, дәвамчанлыкны тәэмин итү максатында гамәлгә ашырыла.

4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы таләпләре нигезендә мәгълүматны кәгазьдә яисә сакланылган элемтә каналлары буенча электрон формада җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Чит кеше ярдәменә даими мохтаҗ граждан ачыкланган очракта, аңа өйдә медицина хезмәте күрсәткәндә, бу хакта мәгълүмат бер эш көне эчендә гражданның яшәү урыны буенча өлкән яшьтәге халыкка беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче Тукай район үзәк хасстаханәсенә гражданинны ачыклаган медицина оешмасы тарафыннан тапшырыла.

4.4. Йорт хуҗалыгында башка теркәлгән затлар булмаган 70 яшьтәге һәм өлкәнрәк яшьтәге гражданнарның йорты (фатиры) буенча йөрү кысаларында чит кеше ярдәменә даими мохтаҗ граждан ачыкланган очракта, яисә гражданинның мөрәҗәгатенә, йә аның мәнфәгатендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, аның тормыш эшчәнлеге шартларын тикшергәндә, бу хакта мәгълүмат социаль хезмәт күрсәтү үзәге тарафынаннан ачыкланган көннән алып бер эш көне эчендә гражданның яшәү урыны буенча социаль яклау бүлегенә җибәрелә.

4.5. Чит кеше ярдәменә даими мохтаҗ гражданин озак вакыт карау буенча социаль хезмәтләр алу буенча мөрәҗәгать иткән очракта яки физик һәм юридик затлардан, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгеннән чит кеше

ярдәменә даими мохтаҗ гражданин турында мәгълүмат кергәндә, Тукай муниципаль районы социаль яклау бүлеге:

- бер эш көне дәвамында өлкән яшьтәге халыкка беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче Тукай үзәк район хастаханәсенә гражданинның яшәү урыны буенча чит кеше ярдәменә мохтаҗ гражданны ачыклау турында мәгълүмат җибәрә;

- түбәндәгеләрне үткәрү өчен, ике эш көне эчендә гражданның яшәү урыны буенча халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге белгечләренең баруын оештыра (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 2019 елның 19 августындагы 637/1652 номерлы уртак боерыгы нигезендә);

а) аның тормыш эшчәнлеге шартларын тикшерү,

б) өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) белән бергә яшәүче һәм аны мөстәкыйль карап тәрбияләүне планлаштыручы туганнарына «Карау-тәрбияләү мәктәбе» стационар алыштыру технологиясе кысаларында карау күнекмәләренә өйрәтү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү,

в) социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) (аның законлы вәкиленә) мәгълүмат бирү,

г) өлкән яшьтәге гражданинның (инвалидның) чит кешеләр ярдәменә бәйлелеген бәяләү (алга таба – типлаштыру), боерыкка 2 нче кушымта нигезендә бәяләү кәгазен тутырып (аның социаль хезмәтләр алырга теләге булган очракта), типлаштыру нәтиҗәләре буенча боерыкка 3 нче кушымта нигезендә өлкән яшьтәге гражданин (инвалид) өчен төркем билгеләү һәм социаль хезмәтләр исемлеген һәм күләмен сайлап алу;

д) өлкән яшьтәге халыкка беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче Тукай район үзәк хастаханәсе, чит кеше ярдәменә даими мохтаҗ гражданин турында, өйдә медицина хезмәте күрсәткәндә мондый гражданны ачыклаган медицина оешмасыннан, территориаль социаль яклау органнарыннан, физик яисә юридик затлардан мәгълүмат алганда:

- мәгълүмат алган көннән соң өч эш көне эчендә гражданга комплекслы бәяләү үткәрү һәм дәвалау-реабилитация чаралары планын төзү оештырыла (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 2019 елның 19 августындагы 637/1652 номерлы уртак боерыгы нигезендә);

- комплекслы бәяләү үткәрелгән көннән соң өч эш көне эчендә медицина оешмасы белешмәләре гражданның яшәү урыны буенча Тукай муниципаль районының социаль яклау бүлегенә җибәрелә;

е) өлкән яштәге халыкка стационар ярдәм күрсәтүче Тукай район үзәк хастаханәсе, чит кеше ярдәменә даими мохтаҗ гражданны ачыклаганда, аңа махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәткәндә:

- махсуслаштырылган медицина ярдәмен күрсәтү чорында комплекслы бәя бирүне үткәрә һәм дәвалау-реабилитация чаралары планын төзи (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 2019 елның 19 августындагы 637/1652 номерлы уртак боерыгы нигезендә);

- махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүнең азаккы көненнән дә соңга калмыйча түбәндәгеләрне юнәлтә:

- өлкән яшьтәге халыкка беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче Тукай район үзәк хастаханәсенә гражданинның яшәү урыны буенча, үтәлешен оештыру өчен, шәхси дәвалау-реабилитация чараларының планын;

- гражданинның яшәү урыны буенчаТукай муниципаль районы социаль яклау бүлегенә (гражданның (аның законлы вәкиленең) язмача мәгълүмати ризалыгы булганда) социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен медицина оешмасы белешмәләрен.

## 5. Мультидисциплинар бригаданың эш принциплары

5.1. Ведомствоара мультидисциплинар бригада үз эшчәнлегендә түбәндәге принципларга таяна:

- медицина ярдәме күрсәтүнең һәм социаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы;
- медицина ярдәмен һәм социаль хезмәт күрсәтүне дә (диагностика, дәвалау, реабилитация, психологик ярдәм күрсәтү, карау) кертеп, кирәкле ярдәм күрсәтүнең өзлексезлеген, дәвамчанлыгын һәм аның барлык өлешләренең үзара бәйләнешен тәэмин итү;
- комплекслылык;
- дәвамчанлык;
- шәхси якын килү.

5.2. Мультидисциплинар бригадалар эшенең әлеге принциплары чит кеше ярдәменә даими мохтаҗ гражданның булган проблемаларын төрле яклап тикшерергә, аларны хәл итүнең оптималь юлларын табарга һәм комплекслы медик-психологик-социаль ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 12 5377 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча**
1 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Яңа поселогы, Иске Гәрдәле авылы, Яңа Сарайлы авылы, Нефтебаза поселогы, Әҗмәкәй авылы.

терапевт, табиб-гериатр:

- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:

- Маликова Эльмира Галимҗан кызы,
- Нуретдинова Нәзилә Шәүкәт кызы,
- Гурьянов Алексей Анатольевич,
- Гыйльфанова Гөлназ Гомәр кызы,
- Крюкова Александра Александровна;

социаль хезмәткәрләр:

- Фазылҗанова Чулпан Рәсим кызы,
- Вәлиева Наталья Николаевна,
- Исламова Гөлфия Миргарифан кызы;

психолог:

- Насырова Ләйсән Каюм кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның _______________ номерлы карарына 3 нче кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
2 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Калмаш авылы, Комсомолец поселогы, Игенче авылы, Белоус авылы, Ильичевка поселогы, Опушка поселогы, Олы Шилнә авылы.

терапевт:
- Абзалтдинова Чәчкә Фәнил кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Кәрамова Фәндәлия Шәмсемөхәммәт кызы,
- Әхмәтсәгыйрова Ландыш Илгиз кызы,
- Нуриева Розалия Заман кызы,
- Әхмәтова Альбина Габдулла кызы,
- Баһаветдинова Рәмзия Зәйнулла кызы;

социаль хезмәткәрләр:
- Гыйләҗева Фәһимә Әхәт кызы,
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:
- Насырова Ләйсән Каюм кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның ____________________ номерлы карарына 4 нче кушымта

**Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча**
3 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Иштирәк авылы, Мартыш авылы, Аулаш авылы, Кама поселогы, Яңа Троицкий авылы, Суровка авылы, Күперле авылы, Шөкрәле авылы, Калиновка авылы.

терапевт:
- Нуриева Айгөл Хәмзә кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Сираева Гөлназ Расих кызы,
- Гариева Айлия Раймир кызы,
- Зайцева Ирина Марсовна,
- Туишева Гөлсирә Ибраһим кызы,
- Драгунова Эльвира Басыйр кызы,
- Лисафьева Ольга Дмитриевна,
- Семенова Елизавета Анатольевна,
- Хәмидуллина Минзифа Рафаэль кызы;

социаль хезмәткәрләр:
- Хәсәншина Гөлнур Суфьян кызы,
- Кәримова Зөбәрҗәт Миргасыйм кызы,
- Хаҗиева Миләүшә Гафият кызы,
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:
- Насырова Ләйсән Каюм кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24.12 ____ 5524 номерлы карарына 5 нче кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
4 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Мәләкәс авылы, Мусабай-Завод авылы, Иске Җирекле авылы, Кызыл Байрак авылы, Калинин авылы, Яңа Җирекле авылы, Куаклы авылы, Ташкичү авылы.

терапевт:
- Галиуллина Рамилә Нәкыйп кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Архипова Акулина Петровна,
- Саттарова Гөлфинә Каим кызы,
- Ягъфәрова Хәмдия Шәрип кызы,
- Гобәйдуллина Ләйлә Нурәхмәт кызы,
- Мифтеева Гөлүсә Зәки кызы,
- Комарова Диләрә Фәиз кызы,
- Ризванова Энҗе Сафи кызы,
- Фәтхуллина Юля Федоровна;

социаль хезмәткәрләр:
- Нурлина Әлфинә Тимергали кызы,
- Мингалимова Илүзә Наис кызы,
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:
- Сәйфуллина Альбина Марс кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 12 ____ 5424 номерлы карарына 6 нчы кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
5 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Борды авылы, Бордыбаш авылы, Җәйләү авылы, Югары Суыксу авылы, Түбән Суыксу авылы, Мазино авылы, Яңа Мусабай авылы, Куады авылы.

терапевт, ревматолог:
- Коләхмәтова Розалия Габдулла кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Ямалиева Алсу Гыйльмулла кызы,
- Хәсәнова Ландыш Әгъзәм кызы,
- Сәитгалиева Нәзилә Рәиф кызы,
- Мингалимова Әлфия Җәүдәт кызы,
- Фәрдиева Миләүшә Хәйдәр кызы,
- Шәрипова Фирдания Гафур кызы,
- Гайнетдинова Гөлнурым Тимофеевна;

социаль хезмәткәрләр:
- Мингалимова Илүзә Наис кызы,
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:
- Сәйфуллина Альбина Марс кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 . 12 5372 номерлы карарына 7 нче кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
6 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Шилнәбаш авылы, Тогаево авылы, Илбухтино авылы.

терапевт:
- Мөхәммәтшина Резеда Инсаф кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Карпова Кристина Михайловна,
- Маркелова Людмила Геннадьевна;

социаль хезмәткәрләр:
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:
- Насырова Ләйсән Каюм кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24.12 № 2774
номерлы карарына 8 нче кушымта

**Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча**
**7 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы**

Торак пунктлар: Биклән авылы, Кызыл Юл авылы, Бакчасарай авылы, Никошновка авылы, Кече Шилнә авылы.

терапевт:
- Сысоева Лилия Аритовна;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Якупова Әнисә Илдархан кызы,
- Харисова Рамилә Рәшит кызы,
- Фәхриева Римма Галимҗан кызы,
- Сафина Гүзәл Галимҗан кызы;

социаль хезмәткәрләр:
- Ганиева Рузалия Фоат кызы,
- Хөснуллина Гүзәлия Вәгыйз кызы,
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:

Сәйфуллина Альбина Марс кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24.12 1528 номерлы карарына 9 нчы кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
8 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Күзкәй авылы, Боерган авылы, Колыш авылы, Таулар авылы, Калмия авылы, Кырныш авылы.

терапевт:
- Юмаев Рифгать Нәҗип улы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Телебаева Роза Мәҗит кызы,
- Гыйльманова Гөлназ Әгъзәмнур кызы,
- Мифтахова Нурсинә Лотфулла кызы,
- Миңнегәрәева Дания Галимҗан кызы,
- Хәкимова Флүзә Фоат кызы,
- Шәйхулахмәтов Фәнис Харас улы;

социаль хезмәткәрләр:
- Әхмәтгәрәева Гөлчәчәк Әхмәтнәҗип кызы,
- Минһаҗева Филига Фарсый кызы,
- Мифтахова Земфира Нәҗип кызы,
- Зәйнуллина Фәнзия Нургали кызы;

психолог:
- Сәйфуллина Альбина Марс кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның ____________ номерлы карарына 10 кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
9 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Туер авылы, Малтабар авылы, Югары Байлар авылы, Яңа Байлар авылы, Иске Байлар авылы.

терапевт:
- Юмаев Рифгать Нәҗип улы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Закирова Люзия Равис кызы,
- Шәйхуләхмәтов Фәнис Харас улы,
- Харисова Зөлфия Мирзаһим кызы,
- Нурмөхәммәтова Гөлнара Әзһәм кызы,
- Гайнетдинова Гөлгенә Фәйзрахман кызы,
- Шәйхулахмәтов Фәнис Харас улы;

социаль хезмәткәрләр:
- Минибаева Эльмира Нәҗип кызы,
- Хаматова Гөлназ Фаяз кызы,
- Зиатдинова Рамилә Рафис кызы,
- Сәлахетдинова Альмира Касыйм кызы,
- Исламова Зөһрә Вәгыйз кызы,
- Кәрамова Фәния Халит кызы,
- Бакирова Айгөл Әхмәтясәви кызы,
- Гәрәева Әкълимә Зәкәр кызы;

психолог:
- Сәйфуллина Альбина Марс кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның ____________________ номерлы карарына 11 нче кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
10 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: «Татарстан» совхозы поселогы, Князево авылы, Сәет авылы, Оргыды авылы, Сосновый бор поселогы, Чыршылы авылы, Сәмәкәй авылы, Күгәш авылы, Казиле авылы.

терапевт:

- Якупова Рәфисә Әбүзәр кызы;
- Юмаев Рифгать Нәҗип улы;

табиб-гериатр:

- Маннапова Алсу Хәмит кызы,

фельдшерлар:

- Гыйләҗева Альбина Равил кызы,
- Юсупов Марат Фәрит улы,
- Фәрдиева Рәзилә Зәки кызы,
- Фаррахова Миләүшә Нуррула кызы,
- Фәйрушина Лира Мәсхүт кызы;

социаль хезмәткәрләр:

- Ахарисова Альбина Әмир кызы,
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:

- Насырова Ләйсән Каюм кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 12 5382 номерлы карарына 12 нче кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
11 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Теләнче-Тамак авылы, Хуҗи авылы, Останково авылы, Таулык авылы.

терапевт:
- Гарипова Илзирә Рөстәм кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

фельдшерлар:
- Харисова Дәйсирә Даугар кызы;

социаль хезмәткәрләр:
- Зарифуллина Гөлия Гарәфи кызы,
- Закирова Рәсимә Муллахмәт кызы,
- Хаҗиева Равилә Нәҗип кызы,
- Закиров Нил Ябир улы;

стационар социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе:
- Зарифуллина Гөлфия Заһир кызы – өлкән шәфкать туташы,
- Хәлимов Рәшид Нурмөхәммәт улы.

психолог:
- Насырова Ләйсән Каюм кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24.12 № 538 номерлы карарына 13 нче кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
12 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пунктлар: Бай-Бүләк авылы, Күктәк-Мирсәет авылы, Иске Теләнче авылы, Казаклар авылы, Таулы Дөреш авылы, Октябрь Бүләге авылы, Салих-Тукай авылы, Яңа Бүләк авылы, Иске Дөреш авылы, Җикәнле Күл авылы, Иске Абдул авылы, Ирек Таңы авылы, Левашево авылы, Мерәс авылы, Торнаташ авылы, Артамоновка авылы.

терапевт:
- Гарипова Илзирә Рөстәм кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы,

фельдшерлар:
- Бәдретдинова Фәнисә Гомәр кызы,
- Рәхимова Наилә Гарифҗан кызы,
- Ахунова Лилия Әнвәр кызы,
- Сәлахова Минзилә Халиткызы,
- Шәйдуллина Гөлназ Алмас кызы,
- Габидуллина Гөлназ Мулланур кызы,
- Габдуллина Флүзә Мөсәвир кызы,
- Әшрафуллина Гөлнара,
- Сәйфетдинова Ләйсирә Хөсәен кызы,
- Бәдретдинова Зөлфия Фирдәвес кызы,
- Закирова Роза Алексеевна,
- Шамсумхаметова Алия Рәшит кызы;

социаль хезмәткәрләр:
- Абдуллина Инзилә Заһир кызы,
- Хаҗиева Равилә Нәҗип кызы,
- Миңнуллина Анастасия Петровна,
- Хәлиуллина Гөлчәчәк Назыйм кызы,
- Дәүләтова Луиза Фелус кызы,
- Галимуллина Энҗе Назыйф кызы;

психолог:
- Насырова Ләйсән Каюм кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның ________ номерлы карарына 14 нче кушымта

Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча
13 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пункт: Бәтке авылы.

терапевт:
- Садыйкова Венера Сәгыйт кызы;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

социаль хезмәткәрләр:
- Закирова Кадрия Фаис кызы,
- Гыйльметдинова Мәрзия Мәхмүт кызы,
- Сөнгатуллина Алсу Мөхәммәт кызы,
- Исламова Гөлфия Миргарифан кызы;

психолог:
- Сәйфуллина Альбина Марс кызы.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 20 12 3884 номерлы карарына 15 кушымта

### Тукай муниципаль районында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү буенча 14 номерлы ведомствоара мультидисциплинар бригада составы

Торак пункт: Круглое Поле поселогы.

терапевт:
- Ермолаева Елена Валерьевна;

табиб-гериатр:
- Маннапова Алсу Хәмит кызы;

социаль хезмәткәр:
- Дементьева Светлана Вильевна;

психолог:
- Сәйфуллина Альбина Марс кызы.